| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.03.2021 ел Баулы шәһәре №43

2021 елда Баулы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын түләүсез туклану белән тәэмин итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, “Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларны тукландыруны оештыру турында” СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү максатларында һәм кайбер категория укучыларга өстәмә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021 елда бушлай туклану белән тәэмин итәргә:

- шәһәр һәм районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә бер үк вакытта укучы 4 һәм аннан да күбрәк балалалары булган күпбалалы гаиләләрдән балаларны;

- гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы “Баулы муниципаль районында “Гаилә” балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют” дәүләт казна учреждениесе балаларын.

2. Баулы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2021 елда җирле бюджетны үтәү барышында бушлай туклану тәэмин итүгә чыгымнарны каплауга финанс чаралары эзләргә.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы Д.З. Ганиевага «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) кулланып, шәһәр һәм районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә бер үк вакытта укучы 4 һәм аннан да күбрәк балалалары булган күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат юллауны (урнаштыруны) тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров